**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Дүрт Мунча авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**24.03.2025** **№ 165**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт Мунча авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында**

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында»2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы 25, 26 статьялары, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Дүрт Мунча авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 32 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт Мунча авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт Мунча авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (кушымта).
2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын, аның график сурәтен дә кертеп, 2025 елның 29 мартыннан да соңга калмыйча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы рәсми сайтында, Дүрт Мунча авыл җирлегенең Дүрт Мунча, Кабан Бастрык, Зычебаш торак пунктлары территорияләрендә түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә:
   - Дүрт Мунча ав., Яшьләр ур., 148 йорт;
   - Дүрт Мунча ав., Үзәк ур., 94А йорт
   - Зычебаш ав., Үзәк ур., 34А йорт;
   - Кабан Бастрык ав., Үзәк ур.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Муниципаль берәмлек башлыгы,**
**Совет Рәисе** **Р.Т.Ситдиков**

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт Мунча авыл җирлеге Советының 2025 елның 24 мартындагы 165 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Дүрт Мунча авыл җирлеге Советы депутатлары сайлаулар уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасы**

**1 нче бермандатлы Зычебаш округы сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 39

Округка Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт Мунча авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Зычебаш авылы, Үзәк урамы №№ 1-50, №№ 88-120 йортлар.

**2 нче бермандатлы Яңа сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 43

Округка Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт Мунча авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Зычебаш авылы, Яңа урамы, №№ 52-66 йортлар, Үзәк урамы, №№ 67-87 йортлар, Дүрт Мунча авылы, Үзәк урамы, №№ 100-116 йортлар.

**3 нче бермандатлы Үзәк сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 48

Округка Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт Мунча авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Дүрт Мунча авылы, Үзәк урамы, №№ 1-19, 63-99 йортлар, Елга аръягы урамы, №№ 20-62 йортлар.

**4 нче бермандатлы Елга аръягы сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 49

Округка Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт Мунча авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Дүрт Мунча авылы, Совет урамы, №№ 64-94 йортлар, Яшьләр урамы, №№ 117-122 йортлар.

**5 нче бермандатлы Яшьләр сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 49

Округка Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт Мунча авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Дүрт Мунча авылы, Яшьләр урамы, №№ 123-129, 133-149 йортлар.

**6 нчы бермандатлы Кабан-Бастрык сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 41

Округка Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт Мунча авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Кабан-Бастрык авылы, Үзәк урамы №№ 1-20, 56-87 йортлар, Дүрт Мунча авылы, Яшьләр урамы, №№ 130-133 йорталар.

**7 нчы бермандатлы Биш-Балта сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 39

Округка Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт Мунча авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Кабан-Бастрык авылы, Үзәк урамы, №№ 21-55, Елга аръягы урамы, №№ 90-119 йортлар, Биш-Балта урамы, №№ 120-132 йортлар.

## Округлар схемасының график сурәте

| Округ № | Төсе | Округ исеме |
|---|---|---|
| 1 | | Зычебаш |
| 2 | | Яңа |
| 3 | | Үзәк |
| 4 | | Елга аръягы |
| 5 | | Яшьләр |
| 6 | | Кабан-Бастрык |
| 7 | | Биш-Балта |

